Республика Татарстан
ЛЯКИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Школьная, д. 1,
с. Ляки, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

Татарстан Республикасы
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛӘКЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

Мәктәп урамы, 1 йорт,
Ләке авылы, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел 7 нче ноябрь № 5

**Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегендә 2024 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Дружба авылында халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башлыгы

КАРАР чыгарды:

1. 2023 елның 17 ноябрендә 13.00 сәгатьтә Сарман муниципаль районы, Дружба авылы, Урман ур., 15 адресы буенча урнашкан 15-нче номерлы йорт янында 2024 елда Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлегенең Дружба авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге Дружба авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидларыннан, сроклы хәрби хезмәт, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт үтәүчеләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү турында һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә килешәсезме:

1) Дружба авылында су коеларын ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләргә һәм хезмәтләргә түләү);

Дружба торак пунктында урам утлары объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм лампалар урнаштыру, килешү буенча эшләргә һәм хезмәтләргә түләү);

"ӘЙЕ " " КАРШЫ?»

3. Әлеге карарны Ләке авыл җирлегенең информацион стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://https://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә бастырырга.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы Антонов Ю.Г.